**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

«23» июнь 2021 ел № 20

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 26 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 26 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар " сүзләрен өстәргә;

2) 29 статьяның 4 пунктына «(булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга .pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга (kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Г.Җиһаншин**